Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары

КАРАР

**10 ноябрь 2021 нче ел** **№1**

«Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлегенең
Иске Кыязлы авылында
гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. 2021 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең Иске Кыязлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эш төрләренә тотуга ризамы"

**1. Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Иске Кыязлы торак пунктындагы Яңа, Яшьләр, М.Җәлил урамнарын төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Кыш көне юлларны кардан чистарту.

**2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлектә яшәүче халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- су челтәрләрен ремонтлау, запас частьләр алу;
- су башнясы өчен 2 данә насос сатып алу;
- су башнялары өчен 2 данәгә басым датчигы сатып алу.

**3. Территорияне төзекләндерү:**

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча башкарылган хезмәтләр өчен түләү).

« ӘЙЕ» "ЮК".

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авылы, Үзәк урам, 57 нче йорт(мәктәп бинасы каршында).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин